ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Татарстан Республикасында гражданнарның сәламәтлеген саклау өлкәсендәге аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» Татарстан Республикасы Законының 11[1] статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 434-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасында гражданнарның сәламәтлеген саклау өлкәсендәге аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» Татарстан Республикасы Законының 11[1] статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 434-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе

БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ
ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ

Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2023 елның 8 июне
№ 2006-VI ДС

проект

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинеты
тарафыннан кертелә

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗАКОНЫ

**«Татарстан Республикасында гражданнарның сәламәтлеген саклау өлкәсендәге аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» Татарстан Республикасы Законының 11$^{1}$ статьясына үзгәрешләр кертү хакында**

**1 статья**

«Татарстан Республикасында гражданнарның сәламәтлеген саклау өлкәсендәге аирам мәсьәләләрне җайга салу турында» 2012 елның 22 декабрендәге 87-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 11$^{1}$ статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2012, № 12 (I өлеш); 2013, № 12 (I өлеш); 2014, № 6 (II өлеш), № 7; 2015, № 3, № 10 (I өлеш); 2016, № 3, № 7 – 8; Татарстан Республикасы законнары җыентыгы, 2016, № 25 (I өлеш); 2017, № 52 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 29 (I өлеш), № 54 (I өлеш), № 83 (I өлеш); 2019, № 28 (I өлеш); 2020, № 26 (I өлеш), № 87 (I өлеш); 2021, № 29 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2022, № 34 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 83 (I өлеш); 2023, № 3 (I өлеш), № 27 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) беренче абзацта «Татарстан Республикасы медицина оешмаларын» сүзләрен «1. Сәламәтлек саклау өлкәсендә Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең вәкаләтле органына буйсынучы оешмаларны» сүзләренә алмаштырырга, «Дәүләт ихтыяҗларын һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарларны, эшләрне, хезмәт күрсәтүләрне сатып алулар өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль законның 93 статьясындагы 1 өлешенең 6 пункты нигезендә сүзләрен төшереп калдырырга;

2) 1 пунктта «Татарстан Республикасы медицина оешмалары» сүзләрен «күрсәтелгән органга буйсынучы оешмалар» сүзләренә алмаштырырга;

3) 3 пунктта «Татарстан Республикасы медицина оешмалары» сүзләрен «сәламәтлек саклау өлкәсендә Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең вәкаләтле органына буйсынучы оешмалар» сүзләренә алмаштырырга;

4) 4 пунктта «Татарстан Республикасы медицина оешмалары» сүзләрен «сәламәтлек саклау өлкәсендә Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең вәкаләтле органына буйсынучы оешмаларга» сүзләренә алмаштырырга;

5) түбәндәге эчтәлектәге 2 өлешне өстәргә:

«2. Әлеге статьяның 1 өлеше нигезләмәләре Россия Федерациясенең норматив хокукый акты белән дәүләт унитар предприятиесе тарафыннан Россия Федерациясе субъектының закон актлары нигезендә бердәнбер тәэмин итүче вәкаләтләрен гамәлгә ашыру мөмкинлеге билгеләнгән очракта кулланыла.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми рәвештә басылып чыккан көннән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**Татарстан Республикасында гражданнарның сәламәтлеген саклау өлкәсендәге аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» Татарстан Республикасы Законының 11[1] статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы закон проектына**
**АҢЛАТМА**

«Татарстан Республикасында гражданнарның сәламәтлеген саклау өлкәсендәге аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» 2012 елның 22 декабрендәге 87-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән (алга таба – Сәламәтлекне саклау турындагы закон) «Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 44-ФЗ номерлы Закон) белән билгеләнгән вәкаләтләргә ярашлы рәвештә «Таттехмедфарм» ДУП медицина оешмаларын, гражданнарның ташламалы категорияләрен дару препаратлары, медицина эшләнмәләре, махсус дәвалау продуктлары, дезинфекцияләү чаралары, чыгым материаллары белән тәэмин итү, шулай ук тиешле товарларны саклау һәм китерү, медицина техникасына хезмәт күрсәтү һәм ремонтлау буенча вәкаләтләрне бердәнбер тәэмин итүче (башкаручы) сыйфатында гамәлгә ашыра дип билгеләнгән.

44-ФЗ номерлы Законга кабул ителгән төзәтмәләргә ярашлы рәвештә 2023 елның 1 июленнән төбәкләрнең күрсәтелгән законга ярашлы рәвештә бердәнбер тәэмин итүчене билгеләү буенча законнар кабул итү хокукы юкка чыгарыла.

Моңа бәйле рәвештә сәламәтлек саклау турындагы 44-ФЗ номерлы Законга сылтаманы алып ташларга кирәк.

Шул ук вакытта Россия Федерациясе субъекты законы белән бердәнбер тәэмин итүчене билгеләү мөмкинлеге, мондый сатып алуларның еллык күләме һәм күрсәтелгән күләмне исәпләү тәртибе кече һәм урта эшкуарлык субъектларының аерым төр юридик затлар тарафыннан товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алуда катнашу үзенчәлекләре турында Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Кече һәм урта эшкуарлык субъектларының аерым төр юридик затлар тарафыннан товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алуда катнашу үзенчәлекләре турында» 2014 елның 11 декабрендәге 1352 номерлы карары белән расланган нигезләмәдә каралган.

Күрсәтелгән Нигезләмәнең 7 пунктында заказчылар төзегән килешүләрнең, шул исәптән кече һәм урта эшкуарлык субъектлары белән, гомуми еллык кыйммәт күләмен исәпләү үзенчәлекләре каралган, алар буенча күрсәтелгән исәп-хисапта сатып алуларның аерым төрләре исәпкә алынмый. Мондый сатып алулар арасында аларны башкару (күрсәтү) бары тик башкарма хакимият органы тарафыннан аның вәкаләтләре яисә аңа буйсынган дәүләт учреждениесе һәм дәүләт унитар предприятиесе нигезендә генә башкарыла ала торган эшләрне (хезмәтләрне) сатып алулар билгеләнгән, аларның тиешле вәкаләтләре федераль законнар, Россия Федерациясе Президентының норматив хокукый актлары яки Россия Федерациясе Хөкүмәтенең норматив хокукый актлары, шулай ук Россия Федерациясенең тиешле субъектының закон актлары белән билгеләнә («и» пунктчасы).

Күрсәтелгән нормадан чыгып, исәп-хисапның билгеләнгән үзенчәлекләрен куллану өчен бердәнбер тәэмин итүче функцияләрен үтәүче дәүләт учреждениесен яки дәүләт унитар предприятиесен закон дәрәҗәсендә билгеләү таләп ителә.

Күрсәтелгән максатларда сәламәтлекне саклау турындагы Законның $11^1$ статьясына тиешле норманы куллану нигезен төзәтеп, үзгәрешләр кертү таләп ителә.

Закон актларында конкрет законга сылтама кулланылмаганга күрә, шулай ук Россия Федерациясе Федераль Җыены Дәүләт Думасы каравында Россия Федерациясе субъекты законнары дәрәҗәсендә дару чараларын һәм башка аерым товарлар һәм хезмәтләрне сатып алганда бердәнбер тәэмин итүчене билгеләргә мөмкинлек бирүче 44-ФЗ номерлы Законга үзгәрешләр кертүне күздә тоткан 119762-8 номерлы федераль закон проекты булуын исәпкә алып, $11^1$ статья нигезләмәләре Россия Федерациясе норматив хокукый актлары белән дәүләт унитар предприятиесе тарафыннан Россия Федерациясе субъектының закон актлары нигезендә бердәнбер тәэмин итүче вәкаләтләрен гамәлгә ашыру мөмкинлеге билгеләнгән очракта кулланыла дип билгеләп, закон проекты белән сәламәтлекне саклау турында законга универсаль нигезләмә кертергә тәкъдим ителә.

Моннан тыш, сәламәтлекне саклау өлкәсендә Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең вәкаләтле органына караган, әмма медицина оешмалары булмаган оешмалар өчен дарулар һәм башка аерым товарлар һәм хезмәтләр сатып алуны тәэмин итү максатларында закон проекты белән «Татарстан Республикасы медицина оешмалары» төшенчәсен «сәламәтлек саклау өлкәсендә Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең вәкаләтле органына буйсынучы оешмалар» дигән сүзләр белән алмаштыру күздә тотыла.

Закон проекты Татарстан Республикасында дару препаратлары белән тәэмин итүнең үзәкләштерелгән тәртибен саклау максатларында, бигрәк тә дустанә булмаган чит ил дәүләтләре һәм халыкара оешмалар эшчәнлеге шартларында, халык өчен мөһим әһәмияткә ия.

**«Татарстан Республикасында гражданнарның сәламәтлеген саклау өлкәсендәге аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» Татарстан Республикасы Законының 11$^{1}$ статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчләрен югалткан дип танылырга, туктатылып торырга, үзгәрешләр кертелергә яки кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары**

**ИСЕМЛЕГЕ**

«Татарстан Республикасында гражданнарның сәламәтлеген саклау өлкәсендәге аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» Татарстан Республикасы Законының 11$^{1}$ статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы законнарын һәм башка норматив хокукый актларын үз көчләрен югалткан дип тануны, туктатып торуны, үзгәрешләр кертүне яки кабул итүне таләп итми.

**«Татарстан Республикасында гражданнарның сәламәтлеген саклау өлкәсендәге аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» Татарстан Республикасы Законының 11[1] статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы закон проектын**

**ФИНАНС-ИКЪТИСАДЫЙ НИГЕЗЛӘҮ**

«Татарстан Республикасында гражданнарның сәламәтлеген саклау өлкәсендәге аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» Татарстан Республикасы Законының 11[1] статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы бюджетыннан өстәмә чыгымнар таләп итми.